| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>СТЕПНОШЕНТАЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>КЫР ШОНТАЛЫ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

с.Степная Шентала

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

09.04.2026 № 16

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 18.11.2018 ел, № 78 карарына үзгәреш кертү хакында (үзгәрешләр белән 07.08.2020 ел, №120 карары)**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә туры китереп, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Кыр Шонталы авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлеге Советының 18 .11.2018 ел, № 78 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (үзгәрешләр белән 07.08.2020 ел, №120 карары) түбәндәге үзгәреш кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) 2,5 % карата:

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган салым салу объектларын, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш;»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Кыр Шонталы авыл җирлеге Башлыгы :** **Г.Н. Кыямова**